Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге
Комаров-завод авылы торак пункыты

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

от «17» ноябрь 2020 ел № 2

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Комаров-завод авылы торак пункыты халык җыены карар итте:

1. 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, балачактан инвалидлар, 90 яшьтән өлкәнрәкләр, ятучы авыруларалар өчен үзара салым суммасының 90% ы күләмендә; тыл хезмәтчәннәре, сугыш чоры балалары, ялгыз аналар, 18 яшькә кадәр балалары булган тол хатыннар, урта һәм югары уку йортларында көндезге формада белем алучы студентлар өчен үзара салым суммасының 50% ы күләмендә ташлама билгеләнүчеләрдән башка 2021 елда Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Комаров-завод авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:
- зират коймаларын төзекләндерү;
- зиратка кадәр юлны төзекләндерү.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) ,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Нөнәгәр авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Нөнәгәр авыл җирлеге башлыгы,
Советы рәисе А. З. Әхмәтханов